Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XX-11**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 24 июле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы депутаты Р. М. Мөхәммәтҗановның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында

Р. М. Мөхәммәтҗановның Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Биектау авыл җирлеге Советы депутаты буларак вәкаләтләре туктатылу сәбәпле, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 маддәсендәге 10.2, 11 өлешләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 29 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 1 өлешенең 9 пункты, 36 маддәсенең 3 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Биектау авыл җирлеге Советыннан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы депутаты Мөхәммәтҗанов Рәфхәт Миңнәхмәт улының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев